**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2020 пгт. Рыбная Слобода № 52пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 26 декабрендәге 331пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 нчы карары, мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты СанПин 2.4.1.3049-13 таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына нигезләнеп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 26 декабрендәге 331пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына кабул ителгән, 2020 елга бала өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап һәм тәрбияләп торганы өчен ата-ана түләве күләме»нә ( кушымта итеп бирелгән) өстәргә һәм расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе  И.М. Садыйковка йөкләргә.

Җитәкче Р. Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма комитеты
2020 елның 12 мартындагы 52пи номерлы
карары белән расланган

**2020 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап һәм тәрбияләп торган өчен**
**АТА-АНАЛАР ТҮЛӘВЕ КҮЛӘМЕ**

1. Гомуми үсеш һәм катнаш юнәлештәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап һәм тәрбияләп торган өчен ата-аналар түләве күләме. 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кергән балалар өчен күчеш чорына балаларны карап һәм тәрбияләп торган өчен ата-аналар түләве күләменә карата төзәтмә коэффициентлары кулланыла. 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына кергән балага исәпләнгән ата – аналар түләве күләменә күчү чорында ул 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен- 0,87, 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр - 0,89 тәшкил итә.
2.

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре | Балалар саны | Бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме-айга сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | |
| | | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 0,87 | 3 яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 0,89 | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |
| | 9 | өчтән ким | 3318 | 2887 | 3345 | 2977 | 465 | 586 |
| | | өч һәм аннан күбрәк | 1660 | 1444 | 1672 | 1488 | 233 | 293 |
| | 10,5 | өчтән ким | 3376 | 2937 | 3375 | 3004 | 465 | 586 |
| | | өч һәм аннан күбрәк | 1688 | 1469 | 1688 | 1502 | 233 | 293 |